СОВЕТ
НОВОШЕШМИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯҢА ЧИШМӘ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

**Татарстан Республикасы**
**Яңа Чишмә муниципаль районы Советы**
**КАРАРЫ**

2018 елның «28» августыннан № 40-228

**«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2015 елның 18 мартындагы 42-248 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында»**

«Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 29 декабрендәге 455-ФЗ номерлы Федераль закон, «Россия Федерациясенең аерым закон актларына мәдәният, сәламәтлек саклау, мәгариф, социаль хезмәт күрсәтү өлкәсендә һәм федераль медико-социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларын бәйсез бәяләүне үткәрүне камилләштерү мәсьәләләре буенча Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 5 декабрендәге 392-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2017 елның 23 декабрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 16 мартындагы 10-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы «муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү хакында» 2015 елның 18 мартындагы 42-247 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы карары нигезендә Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

**КАРАР БИРӘ**:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2015 елның 18 мартындагы 42-248 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

- «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты вәкаләтләре» дип исемләнгән 4 бүлекнең 4.1 пунктының 4 пунктчасында «муниципаль район чикләрендә торак пунктлар чикләреннән читтә

җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын саклау» сүзләреннән соң «юл хәрәкәтен оештыру» сүзләрен өстәргә;

- «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты вәкаләтләре» дип исемләнгән 4 бүлегендәге 4.1 пунктының 1 пунктчасының 9 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- муниципаль берәмлекнең икътисады һәм социаль өлкәсе торышын характерлаучы статистик күрсәткечләр җыюны оештыра һәм күрсәтелгән күрсәткечләрне дәүләт хакимияте органнарына Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә тапшыра;»

- «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты вәкаләтләре» дип исемләнгән 4 бүлекнең 4.1. пунктның 4 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле 12 пунктча өстәргә:

«Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында» 2014 елның 28 июнендәге 172 – ФЗ номерлы Федераль законда каралган стратегик планлаштыруны гамәлгә ашыра»;

- «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты вәкаләтләре» дип исемләнгән 4 бүлегендәге 4.1. пунктының 9 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- федераль законнар белән билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларын бәйсез бәяләүне оештыру өчен шартлар тудыру, шулай ук ведомство буйсынуындагы оешмалар җитәкчеләре эшчәнлеген бәяләгәндә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү шартларын бәйсез бәяләү нәтиҗәләрен куллану һәм федераль законнар нигезендә оешмалар тарафыннан хезмәт күрсәтү сыйфатын бәйсез бәяләү нәтиҗәләре буенча ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү буенча чаралар күрү.";

- «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты вәкаләтләре» дип исемләнгән 4 бүлегендәге 4.1. пунктының 1 пунктчасының 6 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«- «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең социаль-икътисадый үсеш стратегиясен эшли һәм тормышка ашыра»;

- . «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма Комитетының вәкаләтләре» дип исемләнгән 4 бүлекнең 4.1 пунктның 6 пунктчасының 6 пунктчасына сүзен «(волонтерлыкка)» сүзен белән өстәргә ***(2018 елның 1 маеннан үз көченә керә)***;

- «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты вәкаләтләре» дип исемләнгән 4 бүлекнең 4.1. пунктның 5 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле 15 пунктча өстәргә:

« - Яңа Чишмә муниципаль районы территориясендә каты коммуналь калдыкларны җыю, туплау (шул исәптән аерып туплау), ташу, эшкәртү, утильләштерү, зарарсызландыру, күмү эшчәнлеген оештыруда катнашу.» ***(2019 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә)***.

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендәге

Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында http://novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән үзара хезмәттәшлек буенча даими депутат комиссиясенә йөкләргә.

Яңа Чишмә
муниципаль районы Башлыгы В. М. Козлов